РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА АЗНАКАЕВО
АЗНАКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АЗНАКАЙ ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ул.Ленина, д.14, г. Азнакаево, 423330

Ленин ур., 14 йорт,
Азнакай шәһәре, 423330

Тел./факс(885592)7-15-50,7-00-37; E-mail:aznakay@tatar.ru, adm-aznakay@mail.ru;
http://aznakayevo.tatarstan.ru/

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.07.2024 ел. № 27

Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 17 апрелендәге 14 номерлы «Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре бюджетыннан Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәрендә халыкка мунча хезмәтләре күрсәтүне гамәлгә ашыручы юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, физик затларга - хезмәт күрсәтүчеләргә чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) субсидия бирү тәртибе турында»гы карарын үз көчен югалткан дип тану хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Субсидияләр бирүне җайга салучы норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга гомуми таләпләр турында, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне җайга салучы муниципаль хокукый актларга, юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, шулай ук физик затларга - товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер үз көчләрен югалтуын тану турында»гы карарының (2023 елның 1 гыйнварыннан кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр) 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көчен югалтуын исәпкә алып, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан, җирле бюджетлардан субсидияләр бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга гомуми таләпләрне, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар, юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, шулай ук физик затларга - товар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә һәм күрсәтелгән субсидияләрне, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар алучыларны сайлап алуны уздыруга карата гомуми таләпләрне раслау турында» 2023 елның 25 октябрендәге 1782 номерлы карары белән бәйле рәвештә:

1.Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Башкарма комитетының түбәндәге карарларын үз көчен югалткан дип танырга:

- «Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре бюджетыннан Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәрендә халыкка мунча хезмәтләре күрсәтүне гамәлгә ашыручы юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, физик затларга - хезмәт күрсәтүчеләргә чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) субсидия бирү тәртибе турында»гы 2024 елның 17 апрелендәге 14 номерлы карарын;

- «Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре бюджетыннан юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, физик затларга - Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәрендә халыкка мунча хезмәте күрсәтүче хезмәт күрсәтүләргә чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) субсидияләр бирү тәртибе турында»гы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 04 сентябрендәге 38 номерлы карарын.

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Э.Ә. Габдрахманов